Караева, Г. Илдар Юзеев премиясе лауреатлары билгеле / Г. Караева // Шәһри Чаллы. – 2025. – №28 (16 апрель). – Б. 7.

# Илдар Юзеев премиясе лауреатлары билгеле



**10 апрельдә Чаллының 16нчы мәктәбендә Татарстан Язучылар берлеге һәм «ТАТМЕДИА» АҖнең «Мәйдан» журналы редакциясе гамәлгә куйган Илдар Юзеев исемендәге әдәби-иҗтимагый премияләр тапшыру тантанасы үтте.** Кичәдә Татарстанның халык шагыйре, ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, халык язучысы Рабит Батулла, халык шагыйрьләре Газинур Морат, Марсель Галиев, күренекле язучы Ринат Мехәммәдиев, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, Чаллы язучылары, шәһәр хакимияте вәкилләре катнашты.

Әлеге премия шагыйрьнең исемен мәңгеләштерү, иҗатын пропагандалау максатыннан 2005 елда булдырылды. Ул бер ел эчендә«Мәйдан» журналында басылып чыккан иң яхшы әсәрләрнең авторларына һәм шулай ук «Мәйдан» журналын яшәтүгә, аның абруен күтәрүгә зур көч куйган шәхесләргә тапшырыла.

Тантана Илдар аганың улы Салават Юзеевның «Гашыйклар тавы» фильмын күрсәтүдән башланып китте. Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе иясе, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин килгән тамашачыларны сәламләде, Салават Юзеевка этисе әсәре буенча төшерелгән фильм өчен рәхмәтен белдерде.

Аннары мәртәбәле премия лауреатлары игълан ителде. Менә алар:

- «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналының 2024 ел, № 7 санында басылып чыккан «Халык үтмәс үткел юк...» шигырьләр циклы һәм актив әдәби-иҗтимагый эшчәнлеге өчен шагыйрь, язучы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы Фирүзә Ислам кызы Җамалетдинова-Фәтхетдинова;
- Илдар Юзеев иҗатын пропагандалауга керткән өлеше өчен язучы, драматург, режиссер Салават Илдар улы Юзеев;
- «Мәйдан» әдәби-иҗтимагый журналы белән актив хезмәттәшлек иткәне өчен танылган фотожурналист, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия фоторәссамнар берлеге әгъзасы Николай Петр улы Туганов;
- Татар матбугатына, шул исәптән «Мәйдан» әдәби-нәфис, иҗтимагый журналына озак еллар ярдәм иткәне өчен Чаллы шәһәре хакиме ярдәмчесе Рамил Мәрван улы Хәлимов.

Кичәдә уллары хәрби операциядә катнашкан сабыр, олы җанлы солдат әниләре - Сания Хәйретдинова белән Дилбәр Әхәтованы да хөрмәтләделәр. Аларга чәчәк бәйләмнәре һәм бүләкләр тапшырылды.

Чара күмәк төстә «Туган тел» җырын башкару белән тәмамланды.

**Гөлнар Караева**